# КАРАР

**11 апрель, 2024 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында «Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы Березняк авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 11 апрелендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы Березняк авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә Сез ризамы:

- **су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын урнаштыру, ремонтлау;** (янгын гидранты һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)

- **тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау**(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, шәхси электр белән тәэмин итү өчен генератор сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Березняк авылында урам-

юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре); (юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

**- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (Березняк авылы чишмәсе территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, чишмә территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

**- торак пункт территориясен төзекләндерү** *(*Березняк авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, эш өчен шартнамә буенча түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 281 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 144 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 141 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 3 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныrга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы Березняк авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә Сез ризамы:

**- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын урнаштыру, ремонтлау;** (янгын гидранты һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)

- **тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау**(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, шәхси электр белән тәэмин итү өчен генератор сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Березняк авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре); (юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (Березняк авылы чишмәсе территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, чишмә территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **торак пункт территориясен төзекләндерү** (Березняк авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, эш өчен шартнамә буенча түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Березняк
авыл җирлеге башлыгы Р. Ф. Шәрипов